**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 декабрендәге 5495 номерлы карары**

**«2025-2027 елларга Казан шәһәренең**
**торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү»**
**муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы «"Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карарын үтәү йөзеннән, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә һәм Казан шәһәр Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 2-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеш стратегиясенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:

1. «2025-2027 елларга Казан шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасын (алга таба – Программа) әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. 2025 елдан башлап, ел саен Казан шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалыгы комитеты эшчәнлеген тәэмин итүгә һәм чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны программа кысаларында һәм, тиешле бюджет классификациясен кулланып, чираттагы финанс елына бюджетта исәпкә алына торган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (В.А.Лысачкин):

3.1. квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендәге форма буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаның үтәлеше турында хисап тапшырырга;

3.2. ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны әзерләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат юлларга;

3.3. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында расланган Программаны һәм аны гамәлгә ашыру турында еллык хисапны урнаштыруны оештырырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 декабрендәге
5495 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**«2025-2027 елларга Казан шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасы**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | 2025-2027 елларга Казан шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты – гражданнарның, шулай ук шәһәр территориясендәге затларның уңайлы һәм имин яшәү шартларын, халыкны сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү.<br>Программаның бурычлары:<br>торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә муниципаль сәясәтне камилләштерү;<br>- торак-коммуналь хуҗалык инфраструктурасы объектларын саклауны тәэмин итү, агымдагы карап тоту, реконструкцияләү һәм модернизацияләү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2025-2027 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | – |

| | |
|---|---|
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән финанслау күләме | 2025-2027 елларга Программаны финанслау – 3 887 822,40 мең сум, шул исәптән:<br>- 2025 елга – 1 354 345,10 мең сум;<br>- 2026 елга – 1 234 722,30 мең сум;<br>- 2027 елга – 1 298 755,00 мең сум.<br>Финанслау чыганаклары буенча:<br>муниципаль бюджет – 389 469,40 мең сум, шул исәптән:<br>- 2025 елга – 128 123,10 мең сум;<br>- 2026 елга – 129 613,30 мең сум;<br>- 2027 елга – 131 733,00 мең сум;<br>бюджеттан тыш чыганаклар – 3 498 353,00 мең сум, шул исәптән:<br>- 2025 елга – 1 226 222,00 мең сум;<br>- 2026 елга – 1 105 109,00 мең сум;<br>- 2027 елга – 1 167 022,00 мең сум.<br>Финанс ягыннан тәэмин итү фаразлау характерында һәм, Казан шәһәре бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән, еллар буенча бүленгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру 2027 ел ахырына түбәндәге эшләрне башкарырга мөмкинлек бирәчәк:<br>1) 649 күпфатирлы йортны (алга таба – күпфатирлы йорт) капиталь ремонтларга, шул исәптән:<br>- 2025 елда – 184 күпфатирлы йорт;<br>- 2026 елда – 268 күпфатирлы йорт;<br>- 2027 елда – 197 күпфатирлы йорт;<br>2) 128 км озынлыктагы җылылык челтәрләрен алмаштырырга, шул исәптән:<br>- 2025 елда − 42 км;<br>- 2026 елда − 39 км;<br>- 2027 елда − 47 км;<br>3) 561 котельныйны җылылык бирү чорына әзерләргә, шул исәптән:<br>- 2025 елда – 187 котельный; |

| | |
|---|---|
| | - 2026 елда – 187 котельный;<br>- 2027 елда – 187 котельный |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән Программа белән хәл итү каралган мәсьәләләр

Торак-коммуналь хуҗалык – шәһәр хуҗалыгының шәһәрнең яшәешен тәэмин итә торган, социаль яктан әһәмияткә ия тармагы. Программаны гамәлгә ашырганда әлеге программаны куллану өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен исәпкә алырга кирәк. Гамәлгә ашырыла торган чаралар кысаларында муниципаль бюджет акчаларын җәлеп итү өлкәсе еш кына бюджет акчалары юлланган инфраструктура объектларына карата хокукка ия булу белән чикләнгән.

Казан шәһәренең торак фонды түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана:

- торак фондының гомуми мәйданы – 38,8 млн кв.м, шул исәптән 30,2 млн кв.м – күпфатирлы йортлар мәйданы, 0,5 млн кв.м – тулай тораклар мәйданы һәм 8,1 млн кв.м – шәхси торак йортлар һәм блоклап төзелгән йортлар мәйданы;
- төзелгән биналар саны 70 186 йортны тәшкил итә, шул исәптән 5 871 күпфатирлы йорт, 115 тулай торак һәм 64 200 шәхси торак йорт һәм блоклап төзелгән йортлар.

Казан шәһәрендә күпфатирлы йортларның төп өлеше 1940 еллардан соң, 36 проценты 1946 елдан алып 1970 елга кадәр төзелгән. Капиталь ремонт эшләре гаять зур масштабларда үткәрелүгә карамастан, Казан шәһәренең торак фондында әле дә ремонт ясалмаган йортлар күп. 2008-2024 еллар чорында комплексլы рәвештә 1 329 күпфатирлы йорт ремонтланган.

Муниципаль торак фондының мәйданы 671,703 мең кв.м тәшкил итә. Күпфатирлы йортлардагы гомуми милекне карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләме йортларның 90 процентттан артыграгында Казан шәһәре муниципаль торак фонды өчен расланган бәяләр нигезендә билгеләнә.

Тармакның коммуналь секторы «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте, «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте, «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте кебек эре оешмалардан тора. Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2024 елның 29 августындагы 222тд номерлы әмере нигезендә

шәһәрне җылылык белән тәэмин итүнең 2040 елга кадәр актуальләштерелгән схемасы расланды. Шәһәрнең коммуналь инфраструктурасы торак массивларда энергия ресурслары белән тәэмин ителешнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, шулай ук инженерлык челтәрләренең һәм корылмаларының тузу дәрәҗәсе югары (60 проценттан артык) булу белән характерлана. Чиктән тыш канәгатьләнерлек булмаган техник хәлдәге һәм хуҗасыз калган инженерлык челтәрләре урнашкан участоклар булуга бәйле рәвештә, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү максатыннан аларны күчереп урнаштыру һәм яңадан торгызу эшләрен өстәмә финанслау таләп ителә. Шәһәр районнарының урнашу үзенчәлекләрен исәпкә алып, шәһәрнең башка өлешләренә җылылык электр үзәге чыганакларыннан җылылык йөкләнешләрен тарату буенча кыенлыклар бар, бу үз чиратында өстәмә җылылык чыганаклары төзүне таләп итә. Казан шәһәрендә, җиһаз һәм корылмаларның зыянга эшләвенә һәм физик яктан тузуына бәйле рәвештә, милекчеләре җылылык бирү чорында котельныйларын файдаланудан чыгару юлы белән җылылык бирүдән баш тартырга планлаштырган проблемалы ведомство котельныйларына тоташтырылган торак йортларны җылылык белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итәргә кирәк.

Казан шәһәрен су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү схемалары Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 22 ноябрендәге 4782 номерлы «2024 елдан 2028 елга кадәрге чорга Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең административ чикләрендә су белән тәэмин итүнең һәм су чыгаруның актуальләштерелгән схемаларын раслау турында»гы карары белән расланды. Эшләнгән схемаларның төп максатлары булып, су белән тәэмин итүнең һәм су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларын кулланып, абонентлар өчен су белән тәэмин итү һәм су чыгару хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү; су белән тәэмин итүне һәм су чыгаруны, әйләнә-тирә мохиткә аз күләмдә йогынты ясап, иң экономияле ысул белән тәэмин итү; су белән тәэмин итүнең яңа челтәрләрен һәм объектларын төзү; су белән тәэмин итүнең булган объектларын модернизацияләү, реконструкцияләү, кирәк булганда яңа кулланучыларны эшләп килә торган су белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру мөмкинлеген тәэмин итү тора. Су белән тәэмин итү, су чыгару һәм җылылык белән тәэмин итү схемалары муниципаль берәмлекнең үсеш темпларына туры килергә тиеш. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемалары турында»гы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын эшләү һәм раслау кагыйдәләренең 8, 9 пунктлары нигезендә су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын актуальләштерү (төзәтмәләр

кертү) җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарылырга тиеш. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемаларын актуальләштерү су белән тәэмин итү, су чыгару системаларын һәм объектларын яңарту буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен, су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә товарлар белән тәэмин итә торган, хезмәт күрсәтә торган оешмаларның җитештерү һәм инвестиция программаларын эшләү өчен кирәк.

Җылылык белән тәэмин итү схемасын ел саен актуальләштерү зарурлыгы закон дәрәҗәсендә 2010 елның 27 июлендәге 190 номерлы «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы федераль законның 23 статьясындагы 3 пункт белән беркетелгән.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару хезмәтләрен төп гарантияле күрсәтүче булып «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе тора. Предприятие 1,2 млн кешедән артык абонентларны эчә торган су белән тәэмин итә һәм алардан агып чыгучы суларны кабул итә, шәһәрне тәүлек буе су белән тәэмин итү һәм су чыгару буенча шактый өлеше узган гасырның 50-70 елларында салынган 300 артык корылмага, 3,6 мең километрдан артык инженер челтәренә хезмәт күрсәтә. Шәһәр буенча челтәрләрнең һәм корылмаларның гомуми тузуы 70 проценттан артык, гомуми озынлыгы 63 километрдан артык булган челтәрләрне беренчел реконструкцияләү таләп ителә.

## Су белән тәэмин итү

Су белән тәэмин итү челтәрләрендә авария очраклары барлыкка килүнең төп сәбәбе булып моннан 50 ел элек салынган торба үткәргечләрнең 100 процент тузуы тора.

## Су чыгару

Канализация коллекторларында авария очракары барлыкка килүнең төп сәбәбе булып барлыкка килү урынын фаразлап булмаган грунтның кинәт җимерелүе белән бергә баручы тимер-бетон эшләнмәләрнең газ коррозиясе сәбәпле коллекторның өске гөмбәзе җимерелү тора.

Мәсәлән, Яңа Савин районы абонентлары, Совет, Киров районнары абонентларының бер өлеше канализацияләнә торган 3 нче төньяк коллекторда соңгы 8 ел эчендә 50 авария булган, ел саен аварияләр саны арткан, бу торбаүткәргечләрнең тулысынча тузганлыгын күрсәтә. Предприятиенең инвестиция программасы кысаларында бүгенге көндә 2 300 метр торба үткәргечне реконструкцияләү эшләре алып барыла.

Челтәрләр участокларында авария очракларынан килгән гомуми зыян якынча 180 млн сум тәшкил иткән.

Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру гражданнарга мунча хезмәте күрсәтү кебек көнкүреш хезмәтләре күрсәтү өлкәсенә дә кагылды. Бүгенге көндә мунчалар коммерция оешмалары булып тора һәм шәхси милеккә карый, нәтиҗәдә халыкка юыну буенча хезмәт күрсәтү бәяләрен алар мөстәкыйль билгели. Барлыкка килгән традиция буенча җәмәгать мунчалары бүлекчәләренә гадәттә Бөек Ватан сугышы ветераннары, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләр йөри. Әлеге категориягә караган затлар өчен мунчаларның территориаль яктан урнашу урыны мөһим. Мунча яшәү урыныннан ераграк булган саен, аларның сәламәтлеге һәм финанс хәле әлеге хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген чикли.

Шәһәрлеләр арасында уңай мохит тудыру, шикаятьләр санын киметү, шулай ук халыкның аерым категорияләренә ярдәм күрсәтү максатыннан Казан шәһәр Думасы тарафыннан Казан шәһәре территориясендә 1 нче һәм 2 нче разрядлы мунчаларның гомуми бүлекчәләрендә Казан шәһәре территориясендә яшәүче Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм аларны озатып йөрүче затларга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга ташламалы хезмәт күрсәтү, шулай ук Казан шәһәре территориясендә яшәүче пенсионерларга (картлык буенча) 1 октябрьдә, Өлкәннәр көнендә, бушлай хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә алынмый калган керемнәрне каплау өчен оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе эшләнде.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, хәзерге вакытта халыкның уңайлы һәм имин яшәү мохитен формалаштыруга комачаулый торган хәл ителмәгән кайбер мәсьәләләр бар. Алар:

- торак фондының физик яктан шактый тузган булуы;
- хәзерге вакытта эшли торган коммуникацияләрнең тузу дәрәҗәсе югары булу;
- хуҗасыз калган челтәрләрнең һәм объектларның булуы;
- финанс ресурсларының җитәрлек булмавы;
- концессия килешүләреннән тыш, бюджеттан тыш чыганалардан акчалар җәлеп итәргә мөмкинлек бирә торган механизмнарның булмавы.

## II. Программаның максатлары, бурычлары һәм аларны гамәлгә ашыру вакыты, чаралар исемлеге һәм аларның кыскача тасвирламасы

Программа гражданнарны, шулай ук шәһәр территориясендәге затларны яшәү өчен уңайлы һәм имин шартлар, халыкны тиешле дәрәҗәдәге сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар

комплексын үз эченә ала.

Программаның бурычлары:

1. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә муниципаль сәясәтне камилләштерү.

Аңа шәхси кабул итүләр барышында гражданнарны торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча консультация бирү, 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында»гы федераль закон нигезендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү, гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыгу, гамәлдәге законнар кысаларында торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә хокукый актлар чыгару, статистик мәгълүматлар алып бару һәм аларны анализлау, федераль һәм республика максатчан программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу, муниципаль торак контролен башкару юлы белән ирешелә.

2. Торак-коммуналь хуҗалык инфраструктурасы объектларын саклауны тәэмин итү, агымдагы чорда карап тоту, реконструкцияләү һәм яңарту.

Аңа Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча республика программасы составына кертелмәгән торак фондны капиталь ремонтлау программасын гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектларын реконструкцияләү, Казан шәһәре мунчаларында ташламалы категориягә караган гражданнарга бушлай хезмәт күрсәтү юлы белән ирешелә.

Капиталь ремонт программасын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 1 пункт нигезендә торак урыннар хуҗалары акчалары һәм шәһәр бюджеты акчалары ярдәмендә программаны финанслауда катнашуда чагыла.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге, чараларны Казан шәһәре муниципаль бюджеты акчалары һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына финанслау әлеге Программа кушымтасында китерелә.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2025-2027 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын файдалануны һәм капиталь кертемнәргә предприятиеләрнең табышы, амортизация түләүләре һәм

төзүчеләрнең капиталь төзелеш объектларын тоташтыру өчен түләүләр хисабына бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итүне күздә тота.

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Казан шәһәре муниципаль бюджеты** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |
| 2025 | 1 354 345,10 | 128 123,10 | 1 226 222,00 |
| 2026 | 1 234 722,30 | 129 613,30 | 1 105 109,00 |
| 2027 | 1 298 755,00 | 131 733,00 | 1 167 022,00 |
| **БАРЛЫГЫ** | 3 887 822,40 | 389 469,40 | 3 498 353,00 |

Программаны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү фаразлау характерында һәм аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программа белән идарә итү механизмын үз эченә алган Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның төп чаралары, 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль законга таянып, муниципаль заказ башкаручысын билгеләү буенча конкурс процедуралары үткәрү нигезендә гамәлгә ашырылачак. Муниципаль заказны башкаручы белән муниципаль контрактлар төзеләчәк. Эшләрне башкару этаплары, чараларны үтәү вакыты, түләү тәртибе муниципаль контракт нигезендә билгеләнәчәк. Конкурс процедураларын үткәрүдән тыш, бердәнбер тәэмин итүче белән төзелгән муниципаль контракт нигезендә башкарылучы хезмәтләр һәм эшләр (базарда монополия хәлендә торган оешмалар башкара торган хезмәтләр һәм эшләр) бар. Мондый контрактларны төзү шартлары югарыда күрсәтелгән федераль закон белән төгәл билгеләнгән.

Хуҗалык карамагындагы объектларны карап тоту чараларын, шулай ук социаль ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны финанслау муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырылачак. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү мөмкинлеге турында карар кабул ителгәннән соң, сайлап алу нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр белән субсидияләр бирү турында килешүләр төзелә.

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча республика программасы составына кертелмәгән торак фондны капиталь ремонтлау

программасын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 1 пункт нигезендә шәһәр бюджеты акчалары, шулай ук торак урыннар хуҗалары акчалары хисабына финанслауда катнашуда чагыла. Шәһәр бюджеты акчалары идарәче оешмалар счетларына, ә алга таба, капиталь ремонт программасын финанслауда катнашу өчен, төбәк операторы булган «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә нигезләнмәгән оешма счетына күчерелә.

Программа чараларын гамәлгә ашыру кысаларында шәһәр бюджеты акчаларын куллануны контрольдә тоту бюджет законнары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендәге законнар (2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль закон) нигезендә башкарыла.

Программаны гамәлгә ашыруның барлык этапларын да исәпкә алып, аны үтәү, үтәлешен контрольдә тоту Казан шәһәре Башкарма комитетының Тораккоммуналь хуҗалык комитеты хезмәткәрләре тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе, Тышкы төзекләндерү комитеты, Финанс идарәсе, Торак сәясәте идарәсе, Казан шәһәренең Конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар буенча дирекциясе, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары – Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, торак-коммуналь өлкә предприятиеләре һәм оешмалары белән тыгыз элемтәдә торып һәм мәгълүмат алмашып гамәлгә ашырылачак.

Программаның муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 сенә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә расланган форма буенча (Казан шәһәре Башкарма комитеты карарына 2 номерлы кушымта) Программаның үтәлеше турында хисап;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны әзерләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра.

## V. Программаның икътисади, социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү, тиешле финанслау булган очракта, индикаторларның ирешелгән күрсәткечләрен план күрсәткечләре белән чагыштыру аша башкарыла. Тармакның социаль әһәмияткә ия булуын исәпкә алып, Программаны үтәүнең мөһим күрсәткечләре булып социаль нәтиҗәләр торачак. Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләр:

- шәһәр халкына яшәү өчен уңайлы шартлар булдыруны арттыру;
- шәһәр халкы өчен торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген арттыру;
- шәһәрнең яшәү өчен җәлеп итүчәнлеген үстерү;
- шәһәрнең һәм тулаем тармакның инвестицион җәлеп итүчәнлеген үстерү;
- җиһазлар эшендә аварияләр һәм аларның эшләмәү очраклары санын киметү;
- Казан шәһәре халкын үз вакытында җылылык белән тәэмин итү;
- торак-коммуналь хезмәтләрнең канәгатьләнерлек дәрәҗәдә күрсәтелмәве белән бәйле мәсьәләләр буенча шәһәр халкыннан кергән шикаятьләр санының база елы белән чагыштырганда кимүе;
- Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Казан шәһәре Мэры, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм аның урынбасарлары йөкләмәләрен билгеләнгән контроль вакыт аралыгында үтәү;
- Казан шәһәренең 649 күпфатирлы йортында капиталь ремонт үткәрү

___

«2025-2027 елларга Казан шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасына кушымта

**«2025-2027 елларга Казан шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, төп чараларының нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау**

| Төп чаралар атамалары | Башкару чылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| Максат: гражданнарның, шулай ук шәһәр территориясендәге затларның уңайлы һәм имин яшәү шартларын тәэмин итү, халыкны тиешле сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә муниципаль сәясәтне камилләштерү | | | | | | | | | | |
| Үзәк аппаратны агымдагы чорда карап тоту, шул исәптән җир салымын түләү | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты | 2025 - 2027 | - Казан шәһәренең күпфатирлы йортларына ике атна эчендә җылылык җибәрү, %;<br>- түләү вакыты чыккан кредитор бурычлары булу;<br>- хезмәт хакын түләү вакытын бозу;<br>- билгеләнгән | 100<br>0<br>0<br>100 | 100<br>0<br>0<br>100 | 100<br>0<br>0<br>100 | 100<br>0<br>0<br>100 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 45 380,40, шул исәптән җир салымын һәм милеккә салым түләү – 881,80 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 46 870,60, шул исәптән җир салымын һәм милеккә салым түләү – 881,80 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 48 990,30, шул исәптән җир салымын һәм милеккә салым түләү – 881,80 |

| Төп чаралар атамалары | Башкару чылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| | | | контроль вакыт аралыгында башкарылган йөкләмәләр өлеше, %; | 100 (6100 данә) | 95 | 90 | 85 | | | |
| | | | - торак-коммуналь хезмәтләрнең канәгатьләнерлек дәрәҗәдә күрсәтелмәве белән бәйле мәсьәләләр буенча халыктан кергән мөрәҗәгатьләр саны, база елына процентларда; | 897 | 1000 | 1 000 | 1 000 | | | |
| | | | - социаль һәм махсуслаштырылган наем килешүләре һәм аларга өстәмә килешүләр төзү, данә; | 70 | 70 | 70 | 70 | | | |
| | | | - күпфатирлы йортлар белән идарә итә торган оешмаларны сайлап алу буенча ачык конкурслар уздыру, | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| Төп чаралар атамалары | Башкару чылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| | | | данә;<br>- билгеләнгән вакыт аралыгында күрсәтелгән муниципаль хезмәтләр өлеше (бинаны – торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча), % | | | | | | | |
| 2 бурыч. Торак-коммуналь хуҗалык инфраструктурасы объектларын саклауны тәэмин итү һәм агымдагы чорда карап тоту | | | | | | | | | | |
| Торак-коммуналь хуҗалык объектларын капиталь ремонтлау. Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык | 2025 - 2027 | Капиталь ремонт таләп ителә торган күпфатирлы йортларның гомуми саныннан ремонтланган күпфатирлы йортларның өлеше (үсә бару нәтиҗәсе буенча), % | 5,8 | 6,0 | 6,0 | 6,1 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 77 700,00 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 77 700,00 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 77 700,00 |

| **Төп чаралар атамалары** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| буенча республика программасы составына кертелмәгән торак фондын капиталь ремонтлау | комитеты | | | | | | | | | |
| Торак-коммуналь хуҗалык объектларын капиталь ремонтлау. Торак хуҗалыгы өлкәсендәге чаралар (техник заказчы функцияләренең бер өлешен гамәлгә ашыру) | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты | 2025 - 2027 | Капиталь ремонт таләп итеүә торган күпфатирлы йортларның гомуми саныннан ремонтланган күпфатирлы йортларның өлеше (үсә бару нәтиҗәсе буенча), % | 5,8 | 6,0 | 6,0 | 6,1 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 2 000,00 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 2 000,00 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 2 000,00 |

| Төп чаралар атамалары | Башкару чылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| Торак хуҗалыгы өлкәсендә чара (муниципаль торак фондын инвентарьлаштыру) | Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе | 2025 - 2027 | Чараларны гамәлгә ашыру: әйе/юк | Әйе | Әйе | Әйе | Әйе | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты − 1 742,70 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 1 742,70 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты − 1 742,70 |
| Торак-коммуналь хуҗалык объектларын агымдагы чорда карап тоту. Казан шәһәре территориясендә 1 нче һәм 2 нче разрядлы мунчаларның гомуми бүлекчәләрендә Казан шәһәре территориясенд | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты | 2025 - 2027 | 1 нче һәм 2 нче разрядлы мунчаларның гомуми бүлекчәләрендә ташламалы юыну хезмәтеннән файдаланган кешеләр саны, кеше | 2 600 | 2 500 | 2 400 | 2 300 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 1 300,00 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 1 300,00 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 1 300,00 |

| **Төп чаралар атамалары** | **Башкару чылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| ә яшәүче Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм аларны озатып йөрүче затларга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, шулай ук Казан шәһәре территориясендә яшәүче пенсионерларга (картлык буенча) 1 октябрьдә, Өлкәннәр көнендә, бушлай хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә алынмый калган керемнәрне каплау өчен оешмаларга субсидияләр | | | | | | | | | | |

| **Төп чаралар атамалары** | **Башкару чылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| бирү | | | | | | | | | | |
| Гамәлдәге объектларның тузу дәрәҗәсен киметү максатыннан су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларының гамәлдәге объектларын модернизацияләү яисә рекон-струкцияләү | «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе | 2025 - 2027 | Салкын су белән тәэмин итү өчен елга суүткәргеч челтәренең озынлыгына исәпләгәндә аварияләрнең чагыштырмача саны | 0,57 | 0,54 | 0,53 | 0,52 | Бюджеттан тыш чыганаклар (Өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) – 228 361,00 | Бюджеттан тыш чыганаклар (Өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) – 230 034,00 | Бюджеттан тыш чыганаклар (Өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) – 228 155,00 |

| Төп чаралар атамалары | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (база елы) | 2025 | 2026 | 2027 | 2025 | 2026 | 2027 |
| Гамәлдәге объектларның тузу дәрәҗәсен киметү максатыннан суны чыгаруның үзәкләштерелгән системаларының гамәлдәге объектларын модернизацияләү яисә реконструкцияләү | «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе | 2025 - 2027 | Суны чыгару өчен елга канализация челтәренең озынлыгына исәпләгәндә аварияләрнең чагыштырмача саны | 0,14 | 0,08 | 0,07 | 0,07 | Бюджеттан тыш чыганаклар (Өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) – 997 861,00 | Бюджеттан тыш чыганаклар (Өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) – 875 075,00 | Бюджеттан тыш чыганаклар (Өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) – 938 867,00 |
| **Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 128 123,10 | 129 613,30 | 131 733,00 |
| **Бюджеттан тыш чыганаклар хисабына БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 1 226 222,00 | 1 105 109,00 | 1 167 022,00 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 1 354 345,10 | 1 234 722,30 | 1 298 755,00 |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 декабрендәге
5495 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(Форма)

**20___ елның _____________**
**«2025-2027 елларга Казан шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү»**
**муниципаль программасының үтәлеше турында хисап**

| № т/б | Чараның атамасы | Хисап елына программаны финанслауның план буенча күләме, мең сумнарда | | | Хисап чорында программа буенча бүлеп бирелгән акча, мең сумнарда | | | Ел башыннан алып факт буенча файдаланылган (башкаручы счетыннан күчерелгән) акчалар, мең сумнарда | | | Башкару проценты | | | Индикатор атамасы, үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткече | | | | | Нәтиҗәлелекне бәяләү (О), индикаторлар үтәлешенең факттагы проценты буенча |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | шул исәптән | | Барлыгы | шул исәптән | | Барлыгы | шул исәптән | | Барлыгы | шул исәптән | | | 2018 ел (база елы) | агымдагы ел | | | киләсе елга план | |
| | | | Казан шәһәре бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар | | Казан шәһәре бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар | | Казан шәһәре бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар | | Казан шәһәре бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар | | | план | факт | башкару проценты | | |
| 1 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

___________________________